| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ «МИЧУРИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МИЧУРИН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ　　　　　　　　　　　　　　　　КАРАР

2019 елның 29 октябре　　　　　　　　　　　　　　　　№ 12

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Административ регламентларын гамәлдән чыгару турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Гамәлдән чыгарырга:

- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2015 елның 13 ноябрендәге карары белән расланган документларның һәм аларның күчермәләренең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 31 июлендә кабул ителгән карары белән расланган васыятьнамә таныклыгы яки ышанычнамә таныклыгы-нотариаль гамәлләр кылу буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендә кабул ителгән карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент
- Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы « Мичурин авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2018 елның 3 июлендә кабул ителгән карары белән расланган агач һәм куакларны кисүгә, кронировкалауга һәм утыртуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүгә административ регламент

2. Әлеге карарны Мичурин авыл җирлегендә урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә (http://Ieninoqorsk.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Мичурин авыл җирлеге» муниципаль
берәмлеге башлыгы                                                  Р.Ә. Иванова